МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

08.10.2024 № 79

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә үзгәреш кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 ноябрендәге 578 номерлы, 2022 елның 25 августындагы 269 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә үзгәреш кертеп, 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Реестрга түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) муниципальара маршрутның теркәү номеры;

2) муниципальара маршрутның тәртип номеры;

3) муниципальара маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исемнәре яисә чикләрендә шушы маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләр, муниципаль округлар яисә шәһәр округлары исемнәре рәвешендә муниципальара маршрут исеме;

4) муниципальара маршрут буенча аралык тукталыш пунктлары исемнәре яисә чикләрендә аралык тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләр, муниципаль округлар яисә шәһәр округлары исемнәре;

5) муниципальара маршрут буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнар, автомобиль юллары исемнәре;

6) муниципальара маршрутның озынлыгы;

7) пассажирларны утырту һәм төшереп калдыру тәртибе (билгеләнгән тукталыш пунктларында гына яисә, әгәр бу федераль закон белән тыелмаган булса, муниципальара маршрут буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган теләсә кайсы урында);

8) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төре (җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу яисә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу);

9) муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының төрләре, класслары, экологик характеристикалары;

10) муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланырга рөхсәт ителә торган һәр класстагы транспорт чараларының максималь саны;

11) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль, муниципальара, катнаш регионара, регионара маршрутлары реестрларына кертелә торган расписание рәвешен билгеләү турында» 2024 елның 18 апрелендәге 135 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча расписание;

12) ташуларның сыйфатына йогынты ясый торган транспорт чаралары характеристикалары һәм тиешле классны транспорт чараларының максималь исәбендә процентларда мондый характеристикалы һәр класслы транспорт чаралары өлеше;

13) юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлау датасы;

14) (юридик зат өчен) исеме, урнашу урыны, юридик зат төзү турындагы язуның дәүләт теркәү номеры, (шәхси эшкуар өчен) фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның дәүләт теркәү номеры, муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән салым түләүченең идентификация номеры, электрон почта адресы. Әгәр муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бирелгән булса, әлеге белешмәләр гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның һәрберсенә карата күрсәтелә;

15) муниципалитетара маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булу вакыты, әгәр ул федераль закон нигезендә чикләнгән вакытка бирелгән булса;

16) муниципальара маршрутны билгеләү, үзгәртү яисә юкка чыгару турында, җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукын бирү турында карарлар чыгару даталары һәм мондый карарларның реквизитлары.».

Министр Ф.М.Хәнифов